**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзү турында**

2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзергә.

2. 2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-14

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «18» гыйнварындагы
ПУ-14 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Республика оештыру комитеты) Казан шәһәрендә 2022 елда волейбол буенча FIVB дөнья чемпионаты матчларын (алга таба – Чемпионат) әзерләү һәм уздыру, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең (алга таба – органнар һәм оешмалар) Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионатны әзерләү һәм уздыру вакытында үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

2.1. Республика оештыру комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

«2022 елда волейбол буенча ФИВБ дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасына (алга таба – Оештыру комитеты) Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионат белән бәйле чараларны оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтү;

Чемпионатны әзерләү һәм уздыру белән бәйле йөкләмәләрнең үтәлешенә мониторинг уздыру һәм аларны контрольдә тоту;

FIVB таләпләре нигезендә Чемпионат уздыру өчен кирәкле спорт һәм башка инфраструктура объектларын реконструкцияләүне оештыру һәм координацияләү;

Оештыру комитеты белән килештерү буенча Чемпионатны әзерләү һәм уздыру буенча республика комплекслы планын формалаштыру һәм раслау;

Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионатны әзерләү һәм уздыру вакытында органнарның һәм оешмаларның, башка кызыксынган затларның хезмәттәшлеген оештыру;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Оештыру комитеты белән хезмәттәшлеген оештыру һәм килешүләр, гариза кенәгәсе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокукый актлары нигезендә билгеләнгән FIVB алдында йөкләмәләрне үтәүгә булышлык итү;

Чемпионат чараларын әзерләү һәм уздыру максатларында хосусый инвестицияләр җәлеп итүгә булышлык күрсәтү.

## 3. Республика оештыру комитеты функцияләре

3.1. Республика оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара:

үз компетенцияләре чикләрендә FIVB таләпләре нигезендә Чемпионат уздыру өчен кирәкле спорт һәм башка инфраструктура объектларын төзүне һәм реконструкцияләүне оештыру;

Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионатны әзерләү һәм уздыру белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү;

Чемпионатны әзерләү һәм уздыру һәм аның белән бәйле башка чаралар мәсьәләләре буенча органнар һәм оешмаларның килештерелгән карарлар эшләвен һәм кабул итүен оештыру;

органнар һәм оешмаларның, мәгълүмат алмашуны да кертеп, шул исәптән Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча штаттан тыш хәлләргә мөнәсәбәтле гамәлләр кылганда оператив килешенгән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

2022 елда Россия Федерациясендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча координация советына (алга таба – Координация советы) һәм Оештыру комитетына 2022 елда Россия Федерациясендә волейбол буенча FIVB дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча комплекслы план чараларын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионатны әзерләү һәм уздыру белән бәйле башка чараларны гамәлгә ашыру турында хисапларны һәм башка мәгълүматны әзерләү һәм тапшыру;

Координация советына һәм Оештыру комитетына Чемпионатны әзерләү һәм уздыруны норматив-хокукый, оештыру, финанс, мәгълүмати яктан тәэмин итү буенча тәкъдимнәрне әзерләү һәм тапшыру;

Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионат белән бәйле чараларны әзерләү һәм уздыру буенча башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

3.2. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Республика оештыру комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

органнар һәм оешмалардан, башка кызыксынган затлардан билгеләнгән тәртиптә Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратырга;

Оештыру комитетыннан билгеләнгән тәртиптә FIVB техник таләпләрен, оештыручы шәһәрләр, стадионнар, тренировка объектлары, кунакханәләр тарафыннан үз йөкләмәләрен башкару белән бәйле кулланма, ярдәмлек, тәкъдимнәр һәм башка документларны соратырга;

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен эксперт һәм эш төркемнәре төзергә;

FIVB белән килешү нигезендә оештыручы шәһәргә бирелә торган хокукларның куллануын координацияләргә;

үз утырышларына органнар һәм оешмалар, Оештыру комитеты җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен, башка кызыксынган затларны чакырырга;

Чемпионатны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## 4. Республика оештыру комитеты составы

4.1. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4.2. Республика оештыру комитетына рәис, рәис урынбасарлары, секретарь һәм Республика оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы башка әгъзалар керә.

Республика оештыру комитеты составына Чемпионатны әзерләү һәм уздыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләре, кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләре вәкилләре керә.

4.3. Республика оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

4.4. Республика оештыру комитеты рәисе:

Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә;

рәис урынбасарлары һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары арасында бурычларны бүлә;

Республика оештыру комитеты эшчәнлеге планы нигезендә утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

үзе булмаган вакытка Республика оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп үзенең урынбасарларының берсен билгели;

утырыш беркетмәләренә һәм Республика оештыру комитетының башка документларына кул куя.

4.5. Республика оештыру комитеты секретаре:

Республика оештыру комитеты әгъзаларына биш көннән дә соңга калмыйча, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен һәм аның материалларын җибәрә;

Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә;

Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

Оештыру комитеты белән, шул исәптән Чемпионатны әзерләү һәм уздыру белән бәйле мәсьәләләр буенча хезмәттәшлек итә.

4.6. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

Республика оештыру комитеты утырышында шәхсән катнаша;

Республика оештыру комитеты карарларын һәм Республика оештыру комитеты рәисе йөкләмәләрен үти;

Республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

Республика оештыру комитеты карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү, аларның үтәлешенә контрольлек итү буенча кирәкле чараларны башкара.

## 5. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

5.1. Республика оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен, ләкин ким дигәндә өч айга бер тапкыр уздырыла.

5.2. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

5.3. Республика оештыру комитеты утырышлары, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, гамәлгә хокуклы санала. Әгәр утырышта катнашучы әгъзаларының ким дигәндә яртысы Республика оештыру комитеты карарын хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала. Республика оештыру комитеты утырышларында көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә утырышта рәислек итүче кул куя.

5.4. Республика оештыру комитеты кабул итә торган карарлар кызыксынган органнарга һәм оешмаларга, Оештыру комитетына һәм башка кызыксынган затларга җибәрелә.

## 6. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

6.1. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре башкара.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «18» гыйнварындагы
ПУ-14 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2022 елда Казан шәһәрендә волейбол буенча**
**FIVB дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча**
**республика оештыру комитеты**
**составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Мөхәммәтшин<br>Фәрит Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасының Волейбол федерациясе президенты, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Денисов<br>Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры, Республика оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |
| Әгълиуллин<br>Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Афанасьев<br>Андрей Игоревич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсе «Идел буе» чик буе контроль отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Богачев<br>Евгений Борисович | «Уникс» баскетбол клубы президенты (килешү буенча) |
| Брызгалов<br>Олег Георгиевич | «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (Казан шәһәре) (килешү буенча) |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Габдерәшитов<br>Булат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы |
| Гәрәев<br>Марат Мәсгут улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гаффаров<br>Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гомәров<br>Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |

| | |
|---|---|
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Патяшина<br>Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Рәхмәтуллин<br>Илһам Фәиз улы | «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (Казан шәһәре) (килешү буенча) |
| Романцов<br>Сергей Анатольевич | «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасының Казначылык департаменты директоры |
| Фәрдиев<br>Илшат Шәех улы | «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәттахов<br>Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәбибуллин<br>Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хвостиков<br>Игорь Владимирович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Царев<br>Леонид Сергеевич | «Идел буе федераль округы радиоешлык үзәге» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Идел буе федераль округындагы филиалы Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шакирова<br>Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Якубов<br>Таһир Мидхәт улы | «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Тимер юл вокзаллары дирекциясенең структур бүлекчәсе – Горький тимер юл вокзаллары төбәк дирекциясе Казан тимер юл вокзалы башлыгы – Горький тимер юл вокзаллары төбәк дирекциясе башлыгы урынбасары |

___________